СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

22.03.2024 № 8/3

На № ________ от ____________

# КАРАР

**Тукай муниципаль районы Советының 2012 елның 15 августындагы «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^{1}$ статьясы нигезендә түләүсез җир кишәрлекләре алу хокукына ия гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең исемлеген һәм урнашу урынын раслау турында» 14/6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2001 елның 25 январендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Җир кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2003 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 1998 елның 10 июлендәге 1736-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Җир кодексы, «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 18 декабрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль район уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Советының 2012 елның 15 августындагы «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^{1}$ статьясы нигезендә түләүсез җир кишәрлекләре алу хокукына ия гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең исемлеген һәм урнашу урынын раслау турында» 14/6 номерлы карарының 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^{1}$ статьясы нигезендә түләүсез җир кишәрлекләре алу хокукына ия гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең исемлеген һәм урнашу урынын тулыландырырга».

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (https://tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы, Совет рәисе Ф.М. Камаев